**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.12.2016 № 17-148

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында типовой килешү формасын раслау хакында

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 49 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешүнең типовой формасын (алга таба – Типовой форма, килешү) расларга.
2. Килешүләрнең, 2017 елга килешүләрдән башлап, Типовой форма нигезендә булдырылуын билгеләргә.

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
« 22 » декабря 2016 ел № 17-48
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешүнең типовой формасы**

______________ш. «___» ____________ 20__.

*(килешүне төзү датасы)*

____________________________________________________________________________,

*(Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче дәүләт хакимияте башкарма органы (дәүләт органы) атамасы)*

тиешле финанс елына һәм планда каралган чорга Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидия бирүгә бюджет ассигнованиеләре күздә тотылган яки билгеләнгән тәртиптә бюджет йөкләмәләре лимитлары расланган, алга таба - “Гамәлгә куючы” дип атала,

_______________________________________________________________

*(гамәлгә куючының җитәкчесе яки вәкаләтле заты атамасы)*

__________________________________________________ , эш итә

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

_________________________________________________________ нигезендә

*(хакимият органы турында нигезләмә, ышанычнамә, боерык яки башка документ)*

бер яктан, һәм _________________________________________________,

*(Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесе атамасы)*

алга таба - “Учреждение” дип атала, ____________________________________________________________йөзендә

*(Учреждение исеменнән эш итүче вазыйфаи зат атамасы)*

____________________________________________________, эш итә

*(Учреждение исеменнән эш итүченең ФИО)*

____________________________________________________________,

*(Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждение уставы, яисә вәкаләт биргән башка документ)*

икенче яктан, алга таба - “Яклар” дип атала, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә,

_____________________________________________________________________,

*( Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында норматив-хокукый акт атамасы)*

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты _____________________белән расланган , «___» __________20__ ел, № ___ (алга таба – Субсидия бирү тәртибе), бу килешүне (алга таба - Килешү) төзеде.

I. Килешү предметы

1.1. Бу Килешүнең предметы булып 20__ елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба - Субсидия) бирү тора __________________________гә _________________________

*(Учреждение атамасы)* *(субсидия бирү максатын күрсәтергә)*

Татарстан Республикасы дәүләт программасының «__________________________________________________»[1]

*(Татарстан Республикасы дәүләт программасы (программалары) атамасы)*

«__________________________» кече программасы кысаларында.

*(кече программа атамасы)*

---

1 Субсидия Татарстан Республикасы дәүләт программасы (программасы) кысаларында бирелгәндә күрсәтелә

## II. Субсидия күләме

2.1. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия Гамәлгә куючыга, бу Килешүнең 1.1. пунктында күрсәтелгән максатка, Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

2.2. Бу Килешү нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидия күләме

________ (_____________) сум тәшкил итә.

*(сумма сүзләр белән)*

## III. Субсидия бирү шартлары һәм аны күчерү тәртибе

3.1. Субсидия күчерү Учреждениегә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган, Учреждениенең аерым лицевой счетына хәл ителә.

3.2. Субсидия күчерү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан, Гамәлгә куючы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына Учреждениенең акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле документларны һәм Учреждениенең финанс ягыннан тәэмин итү өчен Субсидия бирелә торган акчалата йөкләмәләренең килеп чыгышын раслаган документларны билгеләнгән тәртиптә тапшырганнан соң килгән 2 нче эш көненнән дә соңга калмыйча хәл ителә.

## IV. Якларның хокуклары һәм бурычлары

4.1.Гамәлгә куючы бурычлы:

4.1.1. Россия Федерациясе бюджет законы һәм Субсидия бирү тәртибе нигезендә Субсидия күләмен билгеләүгә.

4.1.2. Учреждениегә бу Килешүнең 3.1 һәм 3.2 пунктларында билгеләнгән

тәртиптә Субсидия күчерүгә.

4.1.3. Учреждениенең бу Килешү шартларын үтәвенә, шулай ук Субсидиядән максатчан файдалануга контрольлекне хәл итүгә, шул исәптән тикшерүләр үткәрү юлы белән.

4.1.4. Россия Федерациясе бюджет законында, Субсидия бирү тәртибендә һәм бу Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәүгә.[2]

4.2. Гамәлгә куючы хокуклы:

4.2.1. Учреждениедән бу Килешүне үтәү өчен кирәкле документлар һәм материаллар сорап алуга, шулай ук бу Килешүнең 4.1.3. пункты нигезендә контрольлекне хәл итүгә.

4.2.2. Түбәндәге очракларда бу Килешүгә үзгәрешләр кертү юлы белән Субсидия күләмен үзгәртүгә:

- тиешле финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләмен яки Гамәлгә куючыга күздә тотылган бюджет йөкләмәләре лимитларын арттыру яки киметү, тормышка ашыруга Субсидия бирелә торган максатларны (чаралар, эшләр составы) тиешенчә үзгәртүдән чыгып;

- тиешле финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында тиешле бюджет ассигнованиеләре булганда һәм Учреждение тарафыннан нигезле заявка тапшырылганда, Учреждениенең өстәмә чыгымнарны хәл кылуга ихтыяҗлары;

- Учреждение тарафыннан Субсидия бирү максатларына ирешүне тәэмин итүгә чыгымнар бу Килешүдә күздә тотылган күләмнән кимрәк булганда, шулай ук Гамәлгә куючы тарафыннан Учреждениенең нигезләнмәгән Субсидия калдыкларына ия булуы турында карар кабул ителгән очракта Субсидия

---

2 Башка конкрет бурычлар күрсәтелә

күләмен шушы калдыклар күләменә киметү зарурилыгы;

- норматив-хокукый актларга, шул исәптән Субсидия бирү буенча чыгым йөкләмәләрен билгеләүче башка максатларга субсидия бирү мәсьәләләрен җайга салган норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү очракларында.

4.2.3. Учреждениегә чираттагы финанс елында Субсидия калдыкларын кире кайтару, аларны шул ук максатка җибәрү ихтыяҗы булганда, турында карар кабул итүгә.

4.2.4. Гамәлгә куючы тарафыннан Субсидиядән файдалану турында хисап тапшыру сроклары санга сугылмаган очракта, Субсидия бирүне туктатып торуга.

4.2.5. Гамәлгә куючы, шулай ук дәүләт финанс контрольлегенең вәкаләтле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча Субсидия бирү тәртибендә һәм бу Килешүдә билгеләнгән максатлар һәм шартларны бозу фактлары ачыкланганда билгеләнгән тәртиптә Субсидия бирүне туктатуга.

4.2.6. Россия Федерациясе бюджет законында, Субсидия бирү тәртибендә һәм бу Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны тормышка ашыруга.

4.3. Гамәлгә куючы бурычлы:

4.3.1. Субсидиядән бу Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү шартлары нигезендә максатчан файдалануга, шул исәптән:

4.3.1.1. Гамәлгә куючы запросы буенча Гамәлгә куючы билгеләгән срокта бу Килешүдә күрсәтелгән Субсидия бирү шартларының үтәлешен тикшерү өчен кирәкле документларны тапшыруга.

4.3.1.2. Гамәлгә куючыга Субсидия күләмен үзгәртүгә йогынты ясардай Субсидиядән файдалану шартларын үзгәртү зарурилыгы турында, мондый үзгәрешләр зарурилыгы ачыклануга,

________________________________________________

*(Гамәлгә куючыга мәгълүмат тапшыруның конкрет срогы күрсәтелергә мөмкин).*

хәбәр итүгә.

4.3.1.3. Гамәлгә куючыга Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнгән формада

________________________________________________________________*(Учреждение тарафыннан Субсидия бирү тәртибе нигезендә Субсидиядән файдалану турында хисап тапшыруның конкрет срогы һәм ешлыгы күрсәтелә)*

шушы сроктан соңга калмыйча Субсидиядән файдалану турында хисап тапшыруга.

4.3.1.4. 1 гыйнварга файдаланылмый калган чираттагы финанс елы Субсидия калдыкларын билгеләнгән тәртиптә кире кайтаруга.

4.3.1.5. Гамәлгә куючы, шулай ук дәүләт финанс конрольлегенең вәкаләтле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча Субсидия бирү тәртибендә һәм бу Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозулар билгеләнгән очракта, файдаланылган Субсидия суммасын Россия Федерациясе бюджет законында билгеләнгән тәртиптә кире кайтаруга.

4.3.1.6. Субсидиядән файдалану буенча факттагы чыгымнар Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнгән срок эчендә тулы күләмендә хәл ителә алмаганда, шулай ук Гамәлгә куючы тарафыннан Учреждениенең нигезләнмәгән Субсидия калдыкларына ия булуы турында карар кабул итү очрагында Гамәлгә куючы карары буенча Субсидияне яки аның бер өлешен (калдыклар суммасын) кире кайтаруга.

4.3.2. Россия Федерациясе бюджет законында, Субсидия бирү тәртибендә һәм бу Килешүдә күздә тотылган башка йөкләмәләрне үтәүгә.

4.4. Учреждение хокуклы:

4.4.1.Гамәлгә куючыга, Субсидия күләмнәрен үзгәртү зарурилыгы килеп туган очракта, бу Килешүгә үзгәрешләр кертү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итүгә (әлеге мөрәҗәгатькә чыгымнарның финанс-икътисадый

нигезләнешен кушып бирергә кирәк).

4.4.2. Гамәлгә куючы тарафыннан чираттагы финанс елында Субсидия калдыкларын Учреждениегә кире кайтару турында карар кабул ителгәндә, аларны шул ук максатка җибәрү ихтыяҗы булганда, агымдагы финанс елында файдаланылмый калган Субсидия калдыкларыннан чираттагы финанс елында файдалануга.

4.4.3. Бу Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә аңлатмалар бирүне сорап Гамәлгә куючыга мөрәҗәгать итүгә.

4.4.4. Россия Федерациясе бюджет законында, Субсидия бирү кагыйдәләрендә һәм бу Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны тормышка ашыруга[3].

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар бу Килешү буенча үз бурычларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

## VI. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Бу Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә Яклар арасында килеп туган бәхәсләр аларның үзләре тарафыннан, мөмкин булганда, тиешле беркетмәләр яки башка документлар нигезендә рәсмиләштерелгән сөйләшүләр юлы белән, хәл ителә. Үзара килешүгә ирешелмәгәндә, Яклар арасында бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

6.2. Килешү Яклар тарафыннан имазланганнан соң үз көченә керә, әмма бу Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгәннән соң гына, һәм, Яклар үзләренең йөкләмәләрен үтәгәнче, «___» _____________ 20__ елга кадәр гамәлдә була.

---

3 Башка конкрет хокуклар күрсәтелә

6.3. Бу Килешүне үзгәртү Якларның тәкъдиме белән язмача, бу Килешүгә өстәмә шартнамә рәвешендә хәл ителә, өстәмә шартнамә Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар кул куйганнан соң үз көченә керә.

6.4. Якларның үзара ризалыгы белән бу Килешүне өзәргә мөмкин.

6.5. Бу килешү ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә, төзелде.

## VIII. Якларның түләү реквизитлары

| | |
|---|---|
| Гамәлгә куючы атамасы | Учреждение атамасы |
| *Гамәлгә куючы атамасы* | *Учреждение атамасы* |
| Урнашу урыны:<br>(*юридик адресы*) | Урнашу урыны:<br>(*юридик адресы*) |
| Түләү реквизитлары: | Түләү реквизитлары: |
| | |

## IX. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Гамәлгә куючының кыскача атамасы<br>______________ | Учреждениенең кыскача атамасы |
| _______________ / _________________<br>*(имза)* *(ФИО)* | _______________ / _________________<br>*(имза)* *(ФИО)* |